ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**17 апрель 2019 ел** **№ 286**

**Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 2 нче февраль 426 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль район Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 ел, 6 нчы октябрь 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 2 нче февраль 426 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль район Советы Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Район Башлыгы урынбасары вәкаләтләре вакытыннан алда Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 21 нче сентябрь, 7 номерлы Карары белән кабул ителгән, Татарстан Республикасв Биектау муниципаль районы Уставының 38 статьясы белән күздә тотылган нигездә туктатыла.»;

2) 25 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кешенең һәм гражданинның хокукларына, ирекләренә һәм вазыйфаларына кагылучы, учредителе муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, алар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керәләр. »

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр буенча комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин